сакларга тырыша, гәрчә кайчагында демографик проблемаларга басым ясасалар да. Шул ук вакытта мондый материалларда дәүләт тарафыннан җитәрлек ярдәм булмау, матди тотрыксызлык, шартлар һәм торак булмау һ.б. сәбәпләр аеручa билгеләнеп үтелә, толерантлык принципларына буйсынып языла.

**Әдәбият:**


1. Бакулина С. Д. Толерантность. От истории понятия к современным социокультурным смыслам. – М.: Флинта, Наука, 2014. – 112 с.
2. Балашов Л.Е. Философия. Учебник. – М.: Дашков и К. 2012. – 612 с.
3. Бондырева С. К. Толерантность. Введение в проблему / С.К. Бондырева, Д.В. Колесов. – М.: МОДЭК, МПСИ, 2013. – 240 с.



***Н.Д. Масалимова***
Казанский (Приволжский) федеральный университет


© Н.Д. Масалимова


***В.З. Гарифуллин***
док. филол. наук, проф.
Казанский (Приволжский) федеральный университет


© В.З. Гарифуллин


## ОТРАЖЕНИЕ В СМИ МЕЖЭТНИЧЕСКИХ И МЕЖКОНФЕССИОНАЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ
## ГАММӘВИ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА ЭТНИКАРА ҺӘМ ДИНИ МӨНӘСӘБӘТЛӘР ЧАГЫЛЫШЫ


***Аннотация.*** *В статье автор раскрывает особенности освещения темы религии в российских СМИ. Автор анализирует количественное соотношение отражения проблем в различных массмедиа.*



***Ключевые слова:*** *религия, межэтнические отношения, межконфессиональные отношения, конфессии.*



***Abstract.*** *He author reveals the peculiarities of the coverage of religion in the Russian media. The author analyzes the quantitative ratio of the reflection of problems in various mass media.*

***Keywords:*** *religion, interethnic relations, interfaith relations, confessions.*

Матбугат җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру инструментларының берсе булып тора, теге яки бу материалның ничек бирелүенә, әлеге материалның киләчәге һәм аның киләчәктә аудитория тарафыннан ничек кабул ителәчәге журналистның бу мәсьәләгә карата фикеренә, мөнәсәбәтенә бәйле.

Барыннан да элек, бу халыкның массакүләм этник аңын һәм массакүләм этник күзаллауларын формалаштыруга кагыла. Матбугаттагы мәгълүматның нәкъ менә толерантлы һәм гуманлы булуына, күп очракта, кешеләрнең уртак тыныч яшәүгә яки милләтара низагларга карашларына бәйле. Шулай итеп, бүгенге көндә формалашкан дини түземлелек проблемасының әһәмияте, актуальлеге, социаль һәм сәяси кискенлеге бәхәссез.

Беренчедән, иҗтимагый тормышны яктыртучы һәм массакүләм аңда толерант һәм конфликтлы кыйммәтләрне, образларны, ориентирларны һәм идеяләрне таратучы массакүләм мәгълүмат чаралары – иҗтимагый аңны формалаштыру һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салуның нәтиҗәле коралы булып тора. Кешеләрнең этник  һәм дини үзенчәлекләре – шулай ук безнең заманыбызның мөһим һәм актуаль күренешләренең берсе. Дөнья тәҗрибәсе әлеге ике феноменның – массакүләм мәгълүмат чараларының һәм мобилизацияләнгән этник сәясәтчеләрнең симбиозы иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә конструктив һәм деструктив роль уйный алуын күп тапкырлар күрсәтә. Массакүләм мәгълүмат чаралары аша аеруча массакүләм аңга тапшырыла торган идеяләр халыкны дезинтеграцияләргә дә мөмкин, без аны Россиянең генә түгел, бөтен дөньяның күп почмакларында да күзәтәбез.

Соңгы елларда Россия һәм дөнья массакүләм мәгълүмат чаралары аша массакүләм аңга зур агым белән этник мәгълүмат тапшырыла. Аның төп мисаллары – этнонимнарны (яки милләтләрне) искә алу, мәсәлән: алман, инглиз, рус, үзбәк, татар һ.б. Матбугаттагы этник мәгълүмат – ул халыклар һәм илләр турында, милли яки этник гореф-гадәтләр һәм кыйммәтләрен чагылдырган язмалар. Бу, әлбәттә, этник сәясәтнең һәм этникара хезмәттәшлекнең чиксез кыры да, бу – этник икътисад, спорт һәм

медицина, педагогика һәм иҗтимагый тормышның башка өлкәләре турында мәгълүмат та. Тик моннан тыш массакүләм мәгълүмат чараларында этниклык – кешеләрнең этник психологиясе, хис-тойгылары, күзаллаулары белән бәйле бик авыр күренешләр дә. Этник мәгълүмат позитив һәм толерант, нейтраль яки конфликтлы булырга мөмкин.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, массакүләм мәгълүмат чараларында тапшырыла торган этник мәгълүмат кешеләрнең милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә массакүләм күзаллауларын формалаштырып кына калмый, ә кешеләрдә үз этник җәмәгатьчелеккә, үз этник яки милли абруена мөнәсәбәт тәрбияли. Шулай итеп, этник үзенчәлекләрне яктыртучы массакүләм мәгълүмат чаралары полиэтник халыкны интеграцияләргә генә түгел, этник хисләр һәм кешеләрнең абруен күтәреп, берләштерергә дә мөмкин. Бер мәкалә шунда ук төрле этник төркем вәкилләре белән бергә яшәүчеләр арасында киеренкелек һәм дошманлык артуга китерергә мөмкин. Россия матбугатында «үз» һәм «чит»ләргә еш бүленеш күзәтелә, ул чакта «читләр» толерант мөнәсәбәт объектларына әйләнәләр.

Журналистларның текстларында толерантлык һәм мультикультурализм принципларын тормышка ашыруы белән беррәттән, дини түземсезлек проблемасы да чагыла. Кызганыч, бөтен дини оешма да толерант түгел, һәр абсолют хакыйкатькә ия булырга дәгъва итә һәм үз тарафдарларының санын арттыру белән кызыксына. Шуңа күрә дини фундаментализмның төрле төрләренә бәйле агымнар, кагыйдә буларак, толерантлыкны кире кага.

Россия матбугатында бүген традицион һәм традицион булмаган диннәргә бүленеш бик кискен тора. Әйтергә кирәк, «традицион булмаган дин» гыйбарәсе тискәре бәя алган, бу бәя «традицион һәм традицион булмаган» диннәр арасындагы аерма, мораль-этик аермалар белән нык бәйләнгән язмалар хисабына ныгытыла. Шуңа күрә хәзерге Россиядә массакүләм мәгълүмат чаралары теләсә кайсы дини мәдәнияткә толерантлык белән карый дип әйтеп булмый. Әгәр православие диненә карата (һәм исламга – халыкның күп өлеше исламда булган төбәкләрдә) журналистлар бик теләп арадашчы-мәгърифәтчеләрнең ролен үз өстенә ала икән, бу алым башка диннәргә кагылмый.

Күпмилләтле Россиядә яшәүче төрле милләт һәм конфессия вәкилләренең тынычлыгы, үзара түземлелеге һәм үзара аңлашуы бу өлкәдә ММЧ эшчәнлегенә бәйле. Россия газеталары битләрендә дини проблемаларны яктырту хәзерге вакытта каршылыклы характерда. Бер яктан, җәмәгатьчелек фикерен сораштырудан билгеле булганча, аудиториянең дин һәм дин мәсьәләләре белән кызыксынуы артуы күзәтелә. Икенче яктан, башка юнәлешләр белән чагыштырганда, дини темага язылган материаллар массакүләм мәгълүмат чараларында аз урын алып тора.

Бүген гаммәви мәгълүмат чараларында дин турында җитди сөйләшү булырга мөмкинме? Бу катлаулы сорауга бер генә җавап юк. Монда кайбер аспектларны аерып карарга була. Соңгы вакытта белгечләр дини тематика белән шөгыльләнүче журналистның нинди булырга тиешлеге һәм бу темага язучы журналистның нинди булырга тиешлеге турында актив фикер алышалар. Белгечләр фикеренчә, «дини проблематика – артык катлаулы һәм җаваплы, бу теманы яктыртуны атеист-белгечләргә тапшырырга мөмкин».

Дини проблеманы яктыртканда, журналистлар стереотип фикер йөртергә тиеш түгел. Бүген гаммәви мәгълүмат чаралары тарафыннан дин мәсьәләләре яктыртылганда, конфессияләр өчен (православие, ислам һәм башка дини юнәлешләр өчен), журналистика өчен дә актуаль проблема туа, барлык кеше дә аңларлык тел тудыру мөһимлеге ачыклана. Изге китаплардан өземтәләр куллану гадәти укучыга проблема тудыра. Шул ук вакытта журналистның да дин өлкәсендә теоретик белемнәре җитеп бетмәве дә проблема.

Федераль һәм төбәк массакүләм мәгълүмат чараларында дини проблемаларны яктырту төрле үзенчәлекләргә ия. Федераль ММЧда хәл катлаулырак. Үзәк массакүләм мәгълүмат чаралары дәүләткә күбрәк буйсына, дәүләт политикасына буйсына, журналистлар ачыктан-ачык үз фикерен белдерә алмый. Төбәк массакүләм мәгълүмат чараларында конфессияара мөнәсәбәтләрне яктырту җирле хакимиятләр сәясәте белән бәйле.

ТР Дәүләт сәясәте ислам һәм православие дине мәнфәгатьләре балансын, тигезлеген саклауга юнәлдерелгән. Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларында дини темаларының яктыртылышын күзәтеп китәргә кирәк.

«Республика Татарстан» газетасында дини-рухи тормышка бик зур игътибар бирелми. Дини проблематикага кагылышлы материалларның күпчелеге дини китаплардан өзекләр, шулай ук зур булмаган язмалар тәшкил итә. Публикацияләр санын бүлүне карап, православие диненә ислам диненә караганда (28%) күбрәк игътибар бирелә дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Бу тенденция алдагы чорда да саклана: 2020-2021 елларда православие һәм исламга багышланган мәкаләләр саны 57% һәм 43% тәшкил иткән.

Басма битләрендә мәгълүмати материаллар белән беррәттән шактый күләмле аналитик язмалар, дин вәкилләре белән әңгәмәләр дә бар. Басмаларда материаллар Христиан һәм Ислам дине арасындагы тыныч бәйләнешне ныгытуга юнәлдерелгән булуын билгеләп үтәргә мөмкин.

Газетаның дини тематикасы шактый төрле: дини бәйрәмнәр, конфессияләрнең эчке тормышы, диннең рухи кыйммәтләрен раслау, дини берләшмәләрнең икътисади эшчәнлеге, дини биналарны торгызу, чиркәү сәнгатен торгызу. Газета дини проблемаларга һәм Татарстан Республикасы өчен традицион конфессияләрнең җәмгыять тормышында катнашуы темасына бик сак мөрәҗәгать итә. Шулай итеп, «Республика Татарстан» газетасы, дин һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерүгә рәсми күзлектән чыгып, конфессияара диалогны яктыртуда һәм дини кыйммәтләрне бәяләүдә үзәк урынны алып тора.

«Время и Деньги» газетасында дини тематиканы яктыртуга зур игътибар бирелә. Мәкаләләр тематикасы шактый төрле. Басмада динара мөнәсәбәтләргә, дини мәгарифкә, дини берләшмәләрнең социаль эшенә, дини һәм дөньяви мәдәниятнең үзара хезмәттәшлегенә, дини берләшмәләрнең көнкүрешкә, икътисадка мөнәсәбәтенә, чиркәү сәнгатенә, дин һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә. Газетада диннең социаль роле һәм кешенең рухи сәламәтлегенә яхшы йогынты ясау темасы иң популяр тема булып тора. Басмада дини берләшмәләр һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр темасы шактый киң яктыртылган. Гомумән алганда, соңгы елларда «Время и Деньги» газетасында дини учреждениеләрнең хәйрия эшчәнлегенә аеруча игътибар бирелә.

Мәкалә текстларында еш кына изге китаптан өземтәләр кулланыла, вәгазь-дидактик тон бар. Исламны яктыртуга караш

башка. Монда беренче урында аналитика тора. Игътибар үзәгендә 2020-2021 елларда ислам турында публикацияләрнең 39% ын тәшкил иткән конфессияләр эчендәге бүленеш һәм дини экстремизм проблемалары тәшкил итә.

Дини экстремизмны профилактикалауга бәйле материаллар (исламда радикал агымнарның асылын аңлатучы, тыелган «Хизб ут-Тахрир», «Ислам җәмәгате» һ.б. дини оешмаларның миссионерлык эшчәнлегенә каршы көрәш чаралары турында сөйләүче) тикшерелүче барлык басмаларда бар.

«Вечерняя Казань» газетасында дини проблемаларга бик аз игътибар бирелә. Газетада аналитик жанрлар да аз тәкъдим ителгән. Биредә православие белемен мәктәпкә кертүгә бәйле берничә язма гына бүлеп бирергә мөмкин. «Интертат» интернет мәгълүмат агентлыгында дини материаллар шактый бай. Аналитик материаллар юк дәрәҗәсендә. Ислам диненә күбрәк басым ясала. Материалларда дөньяда булган кыска хәбәрләр, изге китаптан өзекләрне күрергә була. Аеруча да сихер, бозым темаларына материаллар купшылыгы белән аерылып тора.

Басмада динара мөнәсәбәтләргә, дини мәгарифкә, дини берләшмәләрнең социаль эшенә, дини һәм дөньяви мәдәниятнең үзара хезмәттәшлегенә, дини берләшмәләрнең тормыш эшчәнлеге икътисадына, дин һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә.

***Н.Д. Мухамадиева***
Филиал МБОУ – Верхнекибякозинской средней общеобразовательной школы Тюлячинского муниципального района Республики Татарстан «Малокибякозинская основная общеобразовательная школа»
© Н.Д. Мухамадиева

## ЖИЗНЬ, ПОСВЯЩЕННАЯ ЖУРНАЛИСТИКЕ РОДНОГО КРАЯ
## ТУГАН ТӨБӘК ЖУРНАЛИСТИКАСЫНА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

***Аннотация.*** *Статья посвящена изучению биографии и творческой деятельности известного татарского журналиста Фаниля Нигматзянова. За многие годы самоотверженной*